КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 ноябрь г.Казань № 1267

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карары белән расланган Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 21 июнь, 418 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 796 нчы; 2020 ел, 26 июнь, 534 нче, 2021 ел, 31 май, 420 нче; 2022 ел, 19 февраль, 139 нчы; 2022 ел, 7 июль, 650 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы)

кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

2.13 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бу Тәртипнең 3.1 пунктында күрсәтелгән субсидия бирү нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткечләре (йомгакларның билгеле бер микъдари тасвирнамәсе) һәм төгәл тәмамлану датасы;»;

3.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Шартнамәдә күрсәткечләре билгеләнә торган субсидия бирүнең планлаштырыла торган нәтиҗәләре:».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин